СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

26.01.2016 — № 7-38

с. Набережные Моркваши

«Югары Ослан муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының һәм Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркващы авыл җирлеге Башкарма комитетының авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән һәм авыл җирлекләрендә җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару буенча расланган кагыйдәләр булганда җир кишәрлекләре белән эш итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеге турында килешүне раслау хакында» Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының 2015 елның 24 августындагы 76-359 номерлы карарын юкка чыгару турында

“Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Югары Ослан муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының һәм Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башкарма комитетының авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш буенча расланган кагыйдәләр булганда авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеге турында килешүне раслау хакында» Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының 2015 елның 24 августындагы 76-359 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ____________И. Х. Гаязов